

# Без һәрчак хәрәкәттә

Төркемдәге балаларның күбесе җәй буе өйләрендә ял иттеләр. Алар бакчаны, төркемдәш дусларын, тәрбияче апаларын сагынып килгәннәр. Бергәләшеп балаларның ничек ял итүләре, җәйдән нинди тәэсирләр алулары турында сөйләшеп утырдык. Балалар һәркайсы бер-берсен бүлдерә-бүлдерә яңалыклары белән уртаклаштылар: кемдер авылда кунак булып, әби-бабасына бәбкә-чебиләр үстерешкән һәм үзенә яңа дуслар тапкан. Кемдер дачада әти-әнисенә яшелчә, җиләк-җимеш үстерергә булышкан, ә Исламыбыз ерак җирләргә сәяхәт итәргә дә өлгергән.



Шөгыльләр тәмамлангач, көзнең матурлыгына, көннәрнең әле җылы торуына сөенешеп, көзнең матур мизгелләрен күреп калырга дип, урамга ашыгабыз. Анда безне кызыклы уеннар көтеп тора, әти-әниләр көчә белән бизәлгән матур мәйданчыкта уйнавы да күңелле. «Мәче-тычкан», «Казлар-аккошлар», «Без күңелле балалар», «Ябалак» кебек



хәрәкәтле уеннарны «Оча-очмый», «Диңгез дулкынлана» кебек аз хәрәкәтле уеннар белән аралаштырып оештырабыз. «Миңлебай», «Йөзек салыш» кебек татар халык уеннарын уйнарга да онытмыйбыз. Мәйданчыктагы пароходка утырып, ерак «сәяхәт»кә дә барып кайтабыз.

Кирәк чакта без – тәрбиячеләр, балалар уеннарына юнәлеш бирергә ярдәм итәбез, бергәләп хыялланабыз. Чөнки бала һәрчак хәрәкәттә булганда гына, сау-сәламәт булып үсәчәк.

**Гүзәл ХӘКИМОВА, Әлфирә СӘХӘБИЕВА, Гөлнара МИНДИЯРОВА,**
*Чаллы шәһәре,*
*82нче «Көнбагышкай» балалар бакчасы.*

# Тылсымлы чәчәк

Бер кыз әти-әнисе һәм туганнары белән урманга барган. Урман бик матур икән. Кыз урманның эченәрәк кереп киткән һәм адашкан. Шул арада караңгы төшкән, кыз бик курыккан. Аланда бер чәчәк янып утыра икән. Кыз барып, ул чәчәкне өзгән. Чәчәк телгә килгән һәм болай дигән: «Әй, матур кыз, мине яңадан җиргә утырт. Әбер яфрагымны өзеп алып кал! Ул сиңа өеңә кайтырга ярдәм итәр!»

Кыз шулай эшләгән. Яфрак кызга юл күрсәткән, өенә алып кайткан. Кыз өйгә кайткач, яфракны кибәргә куйган. Ә бер көнне кыз яфракны кулына алган һәм ул телгә килгән:

– Син, матур кыз, мине яшәтәсең. Синең бирәр хыялың бармы? – дип сораган.

Кыз:

– Минем гаиләм белән диңгездә ял итәсем килә, – дигән. Яфрак кызның хыялын тормышка ашырырга сүз биргән.

Шул ук төнне кыз төшендә диңгездә су коенганын күргән, ди.

**Зөлфия ИСРАФИЛОВА,**
*Чаллы шәһәре, 10нчы мәктәп, 2Г сыйныфы.*



Рәсемне буйыйк

# Әкияттә яшибез

Рәхмәт, әни, мине назлый-назлый
Әкият сөйләп кенә йоклаттың.
Рәхәт яшәгез, дип тели-тели
Тормыш юлларына озаттың.

Хәзер адым саен очратабыз
Әкияткә тиң батыр яшьләрнең
Хыялларда гына була дигән,
Чынга ашмас олы эшләрен.

Ниләр генә уйлап чыгармыйлар,
Һәр туган көн – яңа тамаша.
Кибетләргә керсәң рәхәтлектән,
Яңалыктан күзләр камаша.

Үз балама әкият уйлап карыйм,
Килеп чыга никтер чынбарлык.
Һәркөн саен туып тора нидер,
Чын әкияттә яши бар халык...

Әкиятләр сөйләп булмый хәзер,
Без яшибез аның үзендә.
Әкият калды бары үткәннәрдә,
Гаҗәпләнеп торам үзем дә.

Балаларга тыныч тормыш телим
Чынга ашкан әкият илендә.
Теләкләре өчен рәхмәт укыйм
Әниемә туган телемдә!..

**Альбина СӘГЪДИЕВА,**
*Чаллы шәһәре, 82нче балалар бакчасы тәрбиячесе.*

# Әниемнең яшь чагы

Әнием әйтә: «Яшь чакта
Комсомолда идем мин,
Дәреслек, уку, гаделлек
Иң беренче иде, ди.

Эх, үсмер чагым бар иде...
Пионер булган идем.
Муенымда кызыл галстук
Ут кебек яна иде.

Шәп иде балачагымда –
Октябрят булган чорым.
«Йолдызчыклар командиры!» –
Дип аталган вакытым.

Сагынам ла шул чорларны,
Сагынам чын күңелдән!
Вакытны кайтарып булса,
Узар идем киредән».

Минемчә, тарихи чорлар
Булмаганнар начарлар.
Яхшы тормыш корабыз, дип
Тир түккәннәр бит алар.

**Зилә ӘБҮДӘРОВА,**
*Актаныш районы, Теләкәй мәктәбе, 8нче сыйныф.*




## ӘТИ-ӘНИЛӘР КОЛАГЫНА



# Балаң мәктәпкә әзерме?




Балалар мәктәптә укый башлагач, кыенлыклар белән йөзгә-йөз очрашалар. Ата-аналарның күбесе, аларга ничек ярдәм итәргә белмичә, аптырап кала. Кайбер очракларда мәктәпне, укытучыларны гаепләүчеләр дә була. Ләкин килеп чыккан кыенлыкларның сәбәбен ерактанрак эзләргә кирәк. Мәктәпкә укырга килгәнче, сабый нинди күнекмәләр үзләштергән, нинди шартларда яши, сәламәтлеге, физик һәм интеллектуаль үсеше яшенә туры киләме? Бәлки, ата-анасы аны мәктәпкә иртәрәк биргәндер?

6-7 яшьтә баланың физик үсешендә кискен үзгәрешләр барлыкка килә. Аның хәрәкәт системасы (скелет, буыннар, мускуллар) интенсив рәвештә формалаша башлый. Нәкъ менә шул чорда парта артында ул 35-45 минут утырырга мәҗбүр. Дөрес утырмау, озак вакыт хәрәкәтләнмәү нәтиҗәсендә аның умыртка баганасына зарар килергә мөмкин. Бу яшьтәге балалар йөгерү, сикерү, чаңгыда яки тимераякта шуу кебек катлаулырак хәрәкәтләрне оста башкарсалар да, вак мускулларны тиз генә эшкә җигә алмыйлар. Шуңа күрә язган вакытта: «Кулым арыды, авырта» дигән сүзләр еш ишетелә.

Сабыйның мәктәптә яхшы укуын тәэмин итүче мөһим шартларның берсе – хәрәкәт функциясенең (моторика) үсеше. Хәрефләрне һәм цифрларны дөрес һәм төгәл язу, үз-үзеңә хезмәт күрсәтү (төймәләрне каптыру, ботинка бавын бәйләү, физик күнегүләр үтәү) өчен баланың хәрәкәтләре тиешле дәрәҗәдә үскән булырга тиеш. Аз хәрәкәтләнү матдәләр алмашын боза, эшкә сәләтне, авыруларга каршы торучанлыкны киметә. Баланы мәктәпкә 6 яшьтә бирү яки бирмәү мәсьәләсен хәл иткәндә моны истә тотарга кирәк. Чөнки мәктәптә аның өчен иң кыены – хәрәкәт активлыгының кимүе.

Кул чукларының төгәл хәрәкәте матур язу өчен генә түгел, ә баш мие үсеше һәм сөйләм теле формалашу өчен дә әһәмиятле. Шуңа күрә бармаклар өчен күнегүләрне бик иртә (бала 3-4 айлык булгач та) ясый башлау зарур. Бармакларны бөгү, турайту, эре һәм вак әйберләрне тоту, бер савыттан икенчесенә тутыру, шулай ук пластилиннан төрле фигуралар әвәләү, пирамида төзү, кечкенә тишеккә бау кертү, конструктор детальләреннән төрле предметлар төзү һәм җыю бик файдалы.

**Рәйханә ХАММАТОВА,**
*Чаллы шәһәре, 82нче «Көнбагышкай» балалар бакчасы тәрбиячесе.*

Әти-әниләр колагына

# «Өйрәнерләр әле», – димәгез!



Баланы ниндидер эшкә, һөнәргә өйрәтү җиңел түгел. Чөнки эш өйрәтү өчен шактый түземлелек кирәк. «Сиңа өйрәтеп торганчы, үзем тизрәк эшләп куям», йә булмаса: «Аларның пычранганын күтәп тора алмыйм, өйрәнерләр әле», – диючеләр дә бар. Безне әти-әниләр: «Эшләвең минем өчен булса, өйрәнүең үзең өчен», – дип өйрәттеләр. Бу сүзләрне мин дә еш кулландым һәм һаман да кулланам.

Балаларны, беренче чиратта, уенчыкларын юып, җыеп куярга өйрәтергә кирәк. Барлык кирәк-яракларны әзерләп, ничек башларга икәнен күрсәтергә. Алар эшләрен бетергәч, мактый-мактый, шул ук вакытта җайлап кына җитешмәгән якларын да әйтергә. Аннан, алар күрмәгәндә генә, үзегез яңадан юып ала аласыз.

Савыт-саба юганда да нәкъ шулай эшләргә мөмкин. Берәр савыт ватылса да, баланы куркытмыйча (ул болай да куркып кала бит), әкрен генә тынычландырырга кирәк. «Эшләмәгән кеше генә хаталар ясамый, хаталар ясый-ясый өйрәнәсең инде», – диярга була. Мактаган вакытта баланың үзен түгел, ул башкарган эшне мактагыз. Мәсәлән, «Син шул кадәр әйбәт югансың, савытлар ялтырап тора», – дип. Әгәр дә эшне ничек башкарып чыгасын үзегез дә рәтләп белмисез икән, аны балага кушмагыз.

Сүзне тәмамлап шуны әйтәсебез килә: балалар кечкенә вакытта зурларга булышырга яраталар, шул вакытта түземлелек белән өйрәтсәгез, киләчәктә алар сезнең ярдәмчеләрегез булачак.

**Әлфирә ӘХМӘТОВА,**
**Махим КУЗНЕЦОВА,**
*Чаллы шәһәре,*
*82нче «Көнбагышкай» балалар бакчасы тәрбиячеләре.*